РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
**Исполнительный комитет Пестречинского муниципального района**
422770, с. Пестрецы, ул. Советская, 18

**Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы башкарма комитеты**
422770, Питрәч авылы, Совет урамы, 18

тел. +7 (84367) 3-02-02 факс: (84367) 3-02-01E-mail: pitriash@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«07»октябрь, 2019 ел № 1561

Гаиләнең һәр әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең максималь күләмен һәм гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендәге һәм 2019 елның 4 кварталына салым салынырга тиешле мөлкәт хакын раслау турында

Россия Федерациясе Торак кодексы, «Социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннары наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында» 16.03.2015 ел, № 13 –ТРЗ Татарстан Республикасы Законы һәм гаиләнең һәр әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең максималь күләмен һәм гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендәге һәм күрсәтелгән законга кушымтада бәян ителгән салым салынырга тиешле мөлкәт хакын билгеләү методикасы нигезендә, «2019 елның икенче яртыеллыгына Россия Федерациясе буенча торак урынының бер квадрат метр гомуми мәйданы нормативы һәм 2019 елның IV кварталына Россия Федерациясе субъектлары буенча торак урынының бер квадрат метр гомуми мәйданының уртача базар бәясе күрсәткечләре турында» 18.09.2009 елдагы 553/пр номерлы РФ төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы боерыгы белән Питрәч муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. Гражданнарны найм шартнамәсе буенча торак урыны бирүгә мохтаҗлар дип тану турында карар кабул итү өчен максималь әһәмиятләрне билгеләргә:

1.1. Гаилә әгъзалары (ялгыз яшәүче граждан) милкендәге һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакының максималь күләме:

1.1.1. Ялгыз яшәүче граждан өчен-1 637 647,77 сум

1.1.2. Ике кешедән торган гаилә өчен-2 084 253,78 сум

1.1.3. Өч кешедән торган гаилә өчен-2 679 754,86 сум

1.1.4. Дүрт кешелек гаилә өчен-3 573 006,48 сум

1.1.5. Биш кешедән торган гаилә өчен-4 446 25,10 сум

1.1.6. Алты кешедән торган гаилә өчен – 5 359 509,72 сум

1.1.7. Җиде кешедән торган гаилә өчен-6 252 761,34 сум

Гаиләнең һәр әгъзасына туры килә торган уртача айлык җыелма керемнең максималь күләме:

1.1.1. Ялгыз яшәүче граждан өчен-21 327,10 сум

1.1.2. Ике кешедән торган гаилә өчен-13 571,63 сум

1.1.3. Өч кешедән торган гаилә өчен-11 632,82 сум

2.Башкарма комитетның төзелеш, архитектура һәм ТКХ бүлегенә, әлеге карарның 1.1 һәм 1.2 пунктларында күрсәтелгән максималь күләмнәрне найм шартнамәсе буенча торак урыны бирүгә мохтаҗлар буларак исәпкә куелганда кулланырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Муниципаль район
башкарма комитеты җитәкчесе А. В. Хәбибуллин